ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елгы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисап хакында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елгы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан тәкъдим ителгән хисапны карап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елгы эшчәнлеге нәтиҗәләре турындагы хисапны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елгы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисап хакында фикер алышуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутат берләшмәләре вәкилләре, депутатлар тарафыннан әйтелгән тәкъдимнәрне карау һәм кирәкле чаралар күрү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. Татарстан Республикасы Рәисенең 2025 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасында бәян ителгән бурычларны үтәү максатларында алга таба дәүләт органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру эшен гамәлгә ашырырга.

3.2. «Россия Федерациясенең 2030 елга кадәрге чорга һәм 2036 елга кадәр перспективага илкүләм үсеш максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указында билгеләнгән Россия Федерациясенең илкүләм үсеш максатларына ирешү өчен ведомствоара нәтиҗәле эшчәнлекне, шулай ук илкүләм проектлар һәм дәүләт программалары үтәлешен мониторинглауны һәм тикшереп торуны тәэмин итәргә.

3.3. Җәмәгать фикерен мониторинглауны һәм 2025 елга гавами өстенлекләр реестрында билгеләнгән чараларны үтәүне, аларны алга таба гамәлдәге һәм эшләнә торган дәүләт программаларына кертеп, дәвам итәргә, шулай ук кирәк булган очракта законнар белән җайга салу буенча тәкъдимнәр әзерләргә.

3.4. 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясенә анализ ясарга һәм кирәк булган очракта, социаль-икътисадый вәзгыятьтәге үзгәрешләрне исәпкә алып, аңа үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр әзерләргә.

3.5. 2024 – 2025 еллардагы сайлау кампанияләре барышында сайлаучылардан кергән наказларны үтәүне тәэмин итү мөмкинлеген карарга.

3.6. Торак-коммуналь хуҗалыкны модернизацияләү, халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне яхшырту, төп тармак предприятиеләрен кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү эшен оештыруны көчәйтергә.

3.7. Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм алар арасыннан булган хәрби хәрәкәтләр ветераннарына, аларның гаилә әгъзаларына, махсус хәрби операциядә һәлак булган һәм хәбәрсез югалган катнашучыларның гаиләләренә аерым игътибар күрсәтеп, комплекслы ярдәм күрсәтү өчен норматив хокукый базаны камилләштерү мөмкинлеген карарга.

3.8. Законнарны даими мониторинглау нигезендә норматив хокукый базаны камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары белән эшчәнлекне арттырырга, шулай ук Татарстан Республикасы законнарында каралган норматив хокукый актларны үз вакытында кабул итүне тәэмин итәргә.

3.9. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елгы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисапны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 18 апреле
№ 257-VII ДС